Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениясе “Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 8нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе”

| « Каралды » | «Килешенде » | « Раслыйм» |
|---|---|---|
| методик берләшмә утырышында<br>Методик берләшмә җитәкчесе<br>_____________ /Мазитова Л.К./<br>Протокол № 1 « 27 » август 2018 ел | Укыту эшләре буенча директор урынбасары________ /Григорьева Г.Д./<br>« 28 » август 2018 ел | Мәктәп директоры<br>__________ / Граф А.А./<br>Приказ № 253<br>« 29 » август 2018ел |

# 1 нче квалификацион категорияле
# татар теле һәм әдәбияты укытучысы
# Хатыйпова Фәридә Җамалетдин кызының
# рус мәктәбенең (5-9) сыйныфта укучы татар балаларына туган тел ( татар теле ) дәресеннән эш программасы
***база дәрәҗәсе***

**“29” август 2018 нче ел**
**№1 беркетмә белән педагогик**
**киңәшмә утырышында кабул ителде.**

**2018-2019 нчы уку елы**

**“ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУДАН КӨТЕЛГӘН ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ**

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында, татар телен туган тел буларак укытканда, Стандарт нигезендә түбәндәге таләпләр куела:

- укучыларны үз иленең гражданнары һәм патриотлары итеп тәрбияләү, аларны халыкның рухи, әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрен үзләштерердәй итеп үстерү;
- укучыларның рухи-әхлакый сыйфатларын булдыру,

аларның гражданлык, иҗтимагый, шәхси үсешен тәэмин итү, яшь буынның иҗади сәләтен үстерү, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту юнәлешендә эшләү;

- ана теле буенча белем бирүдә эзлеклелекне тәэмин итү;
- балаларга төп белемне сыйфатлы итеп бирү, аларны җәмгыятьтә үз урынын табардай, төрле милләт вәкилләре арасында үзара дус һәм тату яшәрдәй шәхес итеп тәрбияләү;
- белем һәм тәрбия биргәндә, укучыны кабатланмас аерым бер үзенчәлеккә ия булган шәхес итеп күзаллау;
- ана теле дәресләрендә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмнәрендә дөрес һәм тиешенчә куллана белүләренә ирешү, орфоэпик, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы шәхес итеп тәрбияләү;
- балаларда киләчәктә алачак һөнәрләренә аңлы караш тәрбияләү, аларның җәмгыятьтә үз урыннарын таба белүләренә ирешүдә ана теленең әһәмиятен аңлату;
- укучыларны шәхси, иҗтимагый, гаилә таләпләренә туры килердәй белем һәм күнекмәләр белән коралландыруны күз уңында тоту;
- балаларга белем бирүне бердәй сыйфатлы итеп, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикле булганнар да үзләштерердәй итеп оештыру;
- укучылар ала торган белем һәм тәрбиягә бердәй таләпләр белән якын килү, шәхесне киләчәк иҗимагый тормышта үз урынын табардай итеп тәрбияләү;
- уку-укыту эшендә дәрестән тыш формаларны да тиешенчә файдалану;
- төрле клублар, секцияләр, студия һәм түгәрәк эшләре аша укучыларның сәләтен ачыклау, аларга һөнәри юнәлеш алуда ярдәм итү, укуда һәм җәмәгать эшләрендә катнашу аша сәләтле балаларны барлау һәм аларны алга таба үстерү, бу юнәлештә өстәмә белем бирү оешмаларының эшчәнлегенә таяну;
- уку-укыту эшен тиешенчә оештыруда укучылар белән бергә ата-аналар һәм киң җәмәгатьчелек фикерен дә исәпкә алу;
- укучыларда үзләре яши торган төбәккә (авыл, шәһәр, район, бистәгә) карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү, моның өчен ана теле дәресләре белән бергә әдәбият, география, тарих һәм җәмгыять белеме һ.б. дәресләрне дә файдалану.

Предметны үзләштергәннән соң көтелгән нәтиҗәләр өч төрле юнәлештә билгеләнә: шәхси, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләре. Хәзер без предмет нәтиҗәләренең кыскача эчтәлеген санап китәрбез.

Стандарт һәм укыту предметының үзенчәлекләре буенча предмет нәтиҗәләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- укыту предметын нәтиҗәле өйрәнү һәм төрле милләтләр арасында формаль һәм формаль булмаган аралашу өчен кирәк булган дәрәҗәдә сөйләм эшчәнлеге төрләрен камилләштерү;
- белем алу процессында шәхеснең акыл һәм иҗади сәләтен үстерүдә телнең мөһим урын алып торуын аңлау;
- ана теленең аралашу-эстетик мөмкинлекләрен файдалану;
- тел турындагы белемне системага салу, лингвистиканың төп төшенчәләрен үзләштерү;

- сүзгә төрле анализ ясау күнекмәләрен булдыру һәм үстерү (фонетик, морфемик, сүз ясалышы, лексик, морфологик, синтаксик);
- ана теленең әдәби нормаларына (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуацион) һәм татар теленең сөйләм этикеты нормаларына ия булу, аларны телдән һәм язма сөйләм практикасында куллану тәҗрибәсен булдыру;
- тел һәм гомумкешелек кыйммәтләренә җаваплылык белән карау хисе тәрбияләү.

**Танып-белү өлкәсендә:**

- фонетик, сүз төзелеше һәм лексик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык һәм затланышлы фигыльләргә морфологик анализ ясый белү;
- шигъри әсәрләрне сәнгатьле итеп уку;
- мәкальләрнең мәгънәсенә төшенү;
- логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру;
- сөйләм берәмлекләренең хәрәкәтен тоемлый белү.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

«Татар теле» курсын өйрәнүнең метапредмет нәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ).

**Регулятив УУГ (РУУГ):**

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын формалаштыру;
- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр таба белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегенең максатка ирешүдә ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын күзәтү;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль;
- биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Танып-белү УУГ (ТБУУГ):**

- танып-белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә текстның темасын, күтәрелгән проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тел берәмлекләренә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру;

- морфологик берәмлекләрне, төрле чаралардан файдаланып, сөйләм эшчәнлегендә дөрес һәм урынлы файдалана белү;

- телне әдәбият, рәсем һәм музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;

- тел берәмлекләренең әдәби әсәр тудырудагы ролен билгеләү;

- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша телләр арасындагы уртак проблемаларны, уртак кагыйдәләрне, аермалы якларны күрергә өйрәтү;

- сүзлекләрдән, сүзлекчәләрдән, белешмә материаллардан файдалану;

- теге яки бу мәсьәләгә караган фикерне иптәшләренә, укытучыга җиткерү, үз карашыңны дәлилли белергә өйрәтү;

- телне әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру;

- үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.

**Коммуникатив УУГ (КУУГ):**

- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен тормыштагы мисаллар ярдәмендә дәлилли белү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау, автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга чыгыш ясау;
- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар теленә, әдәбиятына һәм башка халыклар теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;

- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;

- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртергә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;

- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үзмаксат кую, үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау;
- үз уңышларыңның яки уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру;

**Әхлакый кыймматләр юнәлеше өлкәсендә:**

- татар теленең, әдәбиятының һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту;

- телнең җәмгыятьтәге ролен ачыклау;
- күнегүләр өчен тупланган текстлар аша укучыны төрле яклап тәрбияләү.

**Коммуникатив өлкәдә:**

- төрле сүз төркемнәрен табу, аларны бер-берсеннән аера белү;
- сүз төркемнәренең мәгънә һәм төзелеш ягыннан төркемчәләрен билгели алу;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;

- укыган текстның эчтәлеген сөйли алу, текст белән бәйле сораулар уйлау, сорауларга җавап бирә алу, телдән монолог, диалог төзү, әңгәмә кору;

- бирелгән темага сочинение, сыйныф яки өйгә бирелгән иҗади эшләр, гомуммәдәният темаларына проект эшләре башкару.

**Эстетик өлкәдә:**

- тел берәмлекләрен сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, алар аша әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әдәби әсәрләрдән рухи тәм табу;

- сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау.

## “ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)” УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| **Программаның төп темалары** | **Сәгать саны** | **Укучыларның төп эшчәнлеге** |
|---|---|---|

| 5 нче сыйныф | | |
|---|---|---|
| **Башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.** | **3** | I-IV сыйныфларда өйрәнгән материалны телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану. |
| **Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография.**<br>Сузык авазлар, аларның сөйләмдәге үзгәреше.<br>Иҗек калыплары.<br>Тартык авазлар, аларның сөйләмдәге үзгәрешләре.<br>Аваз һәм хәреф төшенчәләре. Алфавит.<br>*я, ю, е* хәрефләренең дөрес язылышы.<br>*ъ* һәм *ь* хәрефләренең дөрес язылышы. | **24**<br>4<br>3<br>7<br>3<br>4<br>3 | Авазларны төркемнәргә аеру. Сузык һәм тартык авазларның сөйләмдәге үзгәрешләрен билгеләү. Орфографик сүзлекне файдалану. Сүзнең аваз-хәреф составын чагыштыру. Сүзлекләрдән һәм энциклопедияләрдән кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны файдалану. |
| **Лексика һәм лексикография.**<br>Лексика турында гомуми мәгълүмат.<br>Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре.<br>Татар теленең үз сүзләре.<br>Алынма сүзләр.<br>Һөнәрчелек сүзләре.<br>Актив һәм пассив сүзләр.<br>Искергән сүзләр.<br>Яңа сүзләр.<br>Фразеологизмнар.<br>Сүзлекләр. | **17**<br>1<br>1<br>2<br>1<br>2<br>1<br>1<br>2<br>2<br>2<br>2 | Фикерне һәм хисне белдерүдә сүзнең әһәмиятен аңлау.Сүзнең лексик мәгънәсенә төшенү.<br>Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне аеру.<br>Телдән сөйләмдә алынма сүзләрне, һөнәрчелек сүзләрен, актив һәм пассив сүзләрне файдалану, искергән һәм яңа сүзләрне куллану.<br>Сөйләмдәге фразеологик әйтелмәләрне тану һәм урынлы куллану.<br>Төрле сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу. |
| **Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.**<br>Сүз тамыры.<br>Сүз ясый торган кушымчалар.<br>Сүз формасын үзгәртә торган кушымчалар.<br>Сүз ясалу ысуллары:<br>-ясагыч кушымчалар ярдәмендә сүз ясалу;<br>-сүзләрне кушу яки теркәү ярдәмендә сүз ясау; сүзләрне кыскарту юлы белән яңа сүз ясалу. | **18**<br>2<br>4<br>3<br>2<br>4<br>3 | Ясагыч кушымчаның сүз тамырын һәм кушымчаларны мәгънәле кисәкләр буларак, исем, сыйфат, фигыльләрне ясагандагы әһәмиятен аңлау. Сүзләрне мәгънәле кисәкләргә бүлү.<br>Өйрәнелгән сүз төркемнәреннән исемнәрнең, сыйфатларның һәм фигыльләрнең ясалыш ысулларын аеру.<br>Телдән сөйләмдә һәм язуда сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча булган белем һәм күнекмәләрне ныгыту. |
| **Сөйләм үстерү.** | **11** | Сөйләмне стилистик һәм орфоэпик яктан дөрес итеп оештыру. Укучыларның актив һәм пассив сүзлек байлыгын |

| | | |
|---|---|---|
| | | үстерү. Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү, аны нигезләү. Кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклауга ирешү. |
| **Барлыгы:** | **70** | |
| **6 нчы сыйныф** | | |
| **Кабатлау.** | **3** | |
| **Морфология.**<br>Сүз төркемнәре турында гомуми мәгълүмат. Исем. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Аларның җөмләдә кулланылышы. Исемнәрнең ясалышы. | **59**<br>14 | Сүз төркемнәрен аера белү, аларны телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллана белү күнекмәләрен үстерү.<br>Ике телгә хас булган морфологик күренешләрнең үзенчәлекләрен аңлау. |
| Сыйфат. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Аларның җөмләдә кулланылышы. Сыйфатларның ясалышы. | 8 | Сүз төркемнәренең матур әдәбият әсәрләрендә кулланылу үзенчәлекләрен аңлау, алардан өйрәнелгән сүз төркемнәренә мисаллар табып, сөйләмдә куллана белү осталыгына ирешү. |
| Рәвеш. Рәвеш төркемчәләре. Аларның җөмләдә кулланылышы. Рәвешләрнең ясалышы. | 14 | Рәвешләр белән таныштыру, аларның сыйфатлар белән уртак һәм аермалы якларын күрсәтү, сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру һәм үстерү. |
| Сан. Бүлем, чама һәм җыю саннары. Аларның җөмләдә кулланылышы. Саннарның ясалышы. | 10 | Сөйләмдә сан сүз төркеменең кулланылу үзенчәлекләрен үзләштерү. |
| Алмашлык. Билгеләү, билгесезлек һәм юклык алмашлыклары. Аларның җөмләдә кулланылышы. | 13 | Алмашлык төркемчәләрен бәйләнешле сөйләмдә куллана белү осталыгын үстерү. |
| **Кабатлау** | **8** | Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләренә ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү өчен, төрле сүз төркемнәрен файдалана белү. Татар телен начаррак белүчеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Тәкъдим ителгән текстның планын төзү. Әзер план буенча текст төзү. |
| **Барлыгы:** | **70** | |
| **7 нче сыйныф** | | |

| | | |
|---|---|---|
| **Кабатлау.** | **2** | |
| **Морфология.**<br>Фигыль. Шарт фигыль, аның зат-сан белән төрләнеше, җөмләдә кулланылышы.<br>Хәзерге, үткән һәм киләчәк заман сыйфат фигыльләр. Аларның сөйләмдә кулланылышы.<br>Хәл фигыль һәм аның формалары.<br>Исем фигыль.<br>Инфинитив.<br>Фигыльләрнең ясалышы. | **58**<br>7<br>8<br>8<br>6<br>6<br>3 | Өйрәнелә торган сүз төркемнәреннән фигыльләрне аера, аларны телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллана белү күнекмәләрен үстерү.<br>Төрле сүз төркемнәренең матур әдәбият әсәрләрендә кулланылу үзенчәлекләрен аңлау, алардан өйрәнелгән сүз төркемнәренә мисаллар табып, сөйләмдә куллана белү осталыгына ирешү. |
| Аваз ияртемнәре. Аларның ясалышы, сөйләмдә кулланылышы. | 3 | Аваз ияртемнәренең мөстәкыйль сүз төркемнәре белән уртак билгеләрен үзләштерү, аларның җөмләдә кулланылу очракларына мисаллар табып, телдән һәм язма сөйләмдә куллану. |
| Хәбәрлек сүзләр. Аларның җөмләдә кулланылышы. | 3 | Хәбәрлек сүзләрнең мәгънәләрен аңлап, төрләнү үзенчәлекләрен сөйләмдә куллану. |
| Бәйлекләр. Аларның төркемчәләре. Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләрнең җөмләдә кулланылышы. | 5 | Татар телендә бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең әһәмиятен, урынын аңлау, сөйләмдә дөрес куллана белү. |
| Теркәгечләр. Аларның төркемчәләре, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләре. | 4 | Теркәгечләрнең төркемчәләрен һәм сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен үзләштерү. |
| Кисәкчәләр. Аларның төркемчәләре, дөрес язылышы һәм сөйләмдә кулланылышы. | 4 | Кисәкчәләрнең мәгънә төркемчәләрен, бәйләнешле диалогик һәм монологик сөйләмдә кулланылу очракларын һәм дөрес язылышын истә калдыру. |
| Ымлыклар. Аларның төркемчәләре һәм дөрес язылышы, һәм сөйләмдә кулланылышы.. | 3 | Ымлыкларның сөйләмдәге әһәмиятен, дөрес язылышын һәм кулланылу мөмкинлекләрен үзләштерү. |
| **Сөйләм үстерү.** | **10** | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү өчен, төрле сүз төркемнәрен куллана белүгә ирешү. Татар телендә аралашканда, сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Текст белән эшләү: аңа исем бирү, планын төзү. Тәкъдим ителгән план буенча текст төзү. Русча текстларны татарчага, татарчаларын русчага тәрҗемә итү күнекмәләрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| **Барлыгы:** | **70** | |
| | **8 нче сыйныф** | |
| **Кабатлау.** | **2** | |
| **Синтаксис.**<br>Җөмләнең баш кисәкләре. (кабатлау).<br>Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергыч һәм тәмамлык (кабатлау).<br>Хәл һәм аның төрләре. Хәлләрнең аерымлануы һәм алар янында тыныш билгеләре<br>Татар телендә җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибе, аның рус телендәге сүзләрнең урнашу тәртибеннән аермалы яклары.<br>Гади җөмлә турында башлангычта үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә һәм тойгылы җөмләләр (кабатлау) һәм алар янында куела торган тыныш билгеләре.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.<br>Эндәш сүз һәм кереш сүзләр. Аларны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре. Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.<br>Раслау һәм инкяр җөмләләр, аларның сөйләмдә кулланылышы. | **60**<br>6<br>6<br>20<br>6<br><br>4<br>4<br><br><br>3<br><br>7<br><br>4 | Синтаксисның төп төшенчәләреннән баш һәм иярчен кисәкләрнең белдерелүен аңлау, аларның сөйләмдә кулланылуына төшенү; җөмләнең грамматик нигезен табу; татар һәм рус телләрендә җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибен күзәтү; гади җөмлә төрләрен ачыклау; модаль кисәкләрне билгеләү һәм тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләрен үстерү; телдән һәм язма сөйләмдә гади җөмләләрнең өйрәнелгән төрләрен, җөмлә кисәкләрен диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана белү. |
| **Сөйләм үстерү.** | **8** | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү. Татар телен начаррак белүче кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Текст өстендә эшләү: аңа исем бирү, планын төзү. Тәкъдим ителгән план буенча текст төзү. |
| **Барлыгы:** | **70** | |

| 9 нчы сыйныф | | |
|---|---|---|
| **1.Гади җөмлә синтаксисын кабатлау** | **3** | Хикәя,сорау ,тойгылы җөмләләр.Җөмләләрдә төзүле һәм иялтүле бәйләнешләр. |
| **2.Кушма җөмлә синтаксисы һәм пунктуация** | **46** | Гади һәм кушма җөмләләрне билгели, аларны телдән һәм язма сөйләмдә мөстәкыйль рәвештә куллана белү. |
| Тезмә кушма җөмләләр.Теркәгечле,теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. | 9 | Кушма җөмләләр белән танышу, алар составындагы җөмләләрнең төрлечә бәйләнү очракларын аңлау, сүзләр һәм җөмләләр арасындагы бәйләнеш төрләрен күзәтү. |
| Иярченле кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат. | 4 | Составындагы җөмләләрнең бәйләнеше төрләреннән чыгып, теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр, күптезмәле кушма җөмләләрне диалогик һәм монологик сөйләмдә файдалану, аларны мөстәкыйль рәвештә төзү күнекмәләренә ия булу. |
| Иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш ягыннан төрләре | 3 | Аналитик иярченле кушма җөмләләрнең бәйләүче чаралары һәм аларда кулланыла торган тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләрен үзләштерү. |
| Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре | 30 | Җөмлә кисәкләре белән иярчен җөмлә төрләре арасындагы мәгънә бәйләнешен аңлау. Терминнар арасындагы уртаклыкны һәм сорауларын аңлап куллана белү. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш үзенчәлекләрен аңлау; кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау. |

| | | |
|---|---|---|
| **3.Текст һәм пунктуация**. Текст турында гомуми төшенчә. Туры һәм кыек сөйләм һәм янында тыныш билгеләре. | 11 | Татар әдәби тенең төп нормаларына ия булу; дөрес итеп сөйләшүнең зыялы кешеләргә хас булган билге икәнлеген аңлау; ана теленә хөрмәт белән карау; төп әйтелеш кагыйдәләрен һәм сүз басымының урынын белү; орфоэпик яктан үзеңнең һәм башка кешеләр сөйләмен анализлау һәм бәяләү; сөйләмеңә төзәтүләр кертү; сөйләм культурасын булдыру өчен, татар әдәби телендәге лексик байлыкның мөһимлеген аңлау; хәзерге татар әдәби теле нормалары турында мәгълүматны төрле чыганаклардан алу.<br>Текстларны татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләрен үтәү. |
| **4.Стилистика һәм сөйләм культурасы** | 4 | Татар әдәби тел нормаларына ия булу .Сөйләм культурасын булдыру өчен,әдәби телдәге лексик байлыкнымөһимлеген аңлау.Сөйләмдә туры һәм кыек сөйләмне куллана белү. Алар янында куела торган тыныш билгеләрен урынлы куллану |
| **Кабатлау** | **4** | Үткәннәрне кабатлау. |
| **Барлыгы:** | **68** | |

6 нчы сыйныф татар төркемнәре туган тел(татар теле) дәресеннән календарь тематик план

| № п/п | Бүлек №п/п | Дәрес темасы | Сәг саны | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ПЛАН | ФАКТ |
| **1. 5 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау(3 сәг)** | | | | | |
| 1 | 1.1 | БСҮ “Туган телем-иркә гөлем” | 1 | 4.09 | |
| 2 | 1.2 | Фонетика | 1 | 8.09 | |
| 3 | 1.3 | Сүзнең лексик мәгънәсе,килеп чыгышы,кулланыш өлкәсе | 1 | 11.09 | |
| **2.Морфология (59 сәг)** | | | | | |
| 4 | 2.1 | Сүз төркемнәре турында төшенчә | 1 | 15.09 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 2.2 | Исем турында төшенчә.Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр | 1 | 18..09 | |
| 6 | 2.3 | Исем ясагыч кушымчалар | 1 | 22.09 | |
| 7 | 2.4 | **Исемнәрнең ясалышы ягыннан төрләре** | 1 | 25..09 | |
| 8 | 2.5 | Исемнәрнең ясалышы ягыннан төрләре | 1 | 29.09 | |
| 9 | 2.6 | Исемнәрнең берлек һәм күплек саны формалары | | 2..10 | |
| 10 | 2.7 | **Исемнәрнең килеш белән төрләнеше** | | 6.10 | |
| 11 | 2.8 | БСҮ Изложение№1 “Күке” | | 9.10 | |
| 12 | 2.9 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | | 13.10 | |
| 13 | 2.10 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | 16.10 | |
| 14 | 2.11 | Алынма исемнәрнең төрләнеш һәм әйтелеш үзенчәлекләре | | 20.10 | |
| 15 | 2.12 | Исем сүз төркемнәрен өйрәнүгә | | 23.10 | |

# Белем  һәм осталык күнекмәләрен бәяләү нормалары

Укучыларның тел һәм сөйләм материалын үзләштерү дәрәҗәсен яки аларның гомуми грамоталылыгын диктант, изложение, сочинение яздырып тикшереп була; сорауларга язма рәвештә җавап алу да уңай нәтиҗә бирә. Сораулар укыган әсәр, аерым текст, рәсем яки караган фильмнар буенча тәкъдим ителә. Бу очракта язма эшнең күләме һәр сыйныфның изложение күләменнән артмый. Укытучы, эшне бәяләгәндә, түбәндәге таләпләрне истә тотарга тиеш: җавапның тулы, төгәл, дөрес булуы, сөйләмнең стилистик яктан камиллеге, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталылыгы.

## Сорауларга җавап язуны бәяләү

Барлык сорауларга да дөрес җавап бирелсә, «5» ле куела (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хата булырга мөмкин).

Сорауларга дөрес җавап бирелсә, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрелсә, «4» ле куела.

Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәләре сизелсә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хата булса, «3» ле куела.

Җавапларның яртысы дөрес булмаса, сөйләм хаталары 3 тән артса, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

## Сүзлек диктантын бәяләү

1. Пөхтә итеп язылган, хатасы булмаган эшкә «5» ле куела.

2 1-2 орфографик хаталы эшкә «4» ле куела.

3. 3-4 орфографик хаталы эшкә «3» ле куела.

4. 5 һәм аннан күбрәк хаталы эшкә «2» ле куела.

## Диктантларның күләме һәм аларны бәяләү

Диктант - укучының гомуми грамоталылыгын тикшерү өчен уздырыла торган язма эшнең бер төре. Диктантлар өйрәтү һәм контроль төрләргә бүленә.

Өйрәтү диктантлары берничә төрле була: сүзлек диктанты, искәртмәле, аңлатмалы, сайланма, иҗади, күрмә, хәтер, ирекле диктантлар.

1. Орфографик хатасы булмаса, «5» ле куела (1 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булса, «4» ле куела.

3. 1 орфографик, 2 пунктуацион хатасы булса, «3» ле куела.

4. 5 орфографик, 4-6 пунктуацион хатасы булса, «2» ле куела.

Өйрәтү диктантлары 5-7 нче сыйныфларда ешрак яздырыла.

## Контроль диктантны бәяләү

| Билге | Хаталар саны |
|---|---|
| «5» ле | 0/0, 0/2, 1/0 пөхтә эшкә |
| «4» ле | 2-3/3-2 |
| «3» ле | 4/4, 3/6 |
| «2» ле | 6/5,5/8 |

## Изложение язу

Изложение яздыру өчен, матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр, хикәяләр, аерым текстлар алына. Алар эчтәлеге һәм күләме ягыннан тиешле таләпләргә җавап бирергә, тәрбияви максатларны үз эченә алырга һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, камилләштерү юнәлешендә булырга тиеш. Изложение ярдәмендә укучының тема эчтәлеген ача белү осталыгы, лексик байлыгы, орфография, грамматика, пунктуация өлкәсенә караган грамоталылыгы тикшерелә. Бу вакытта яңа сүзләр һәм тәгъбирләрне аңлатырга, аларны тактага язып куярга кирәк.

Изложениене бәяләгәндә, фикерләрнең логик эзлеклелегенә, эчтәлекнең тулы, дөрес бирелүенә, язма сөйләм теленең камиллегенә, грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсенә игътибар ителә.

Изложение һәм сочинение өчен ике билге куела: беренчесе - эчтәлек һәм сөйләмне дөрес оештыра алуга, икенчесе - грамоталылыкка.

## Изложениене бәяләү

1. Тема тулысынча ачылган, эчтәлеге һәм стиль бердәмлеге сакланган эшкә «5» ле куела (1 орфографик, 2 пунктуацион яки 2 грамматик хатасы булырга мөмкин).

2. Текстның эчтәлеге темага, нигездә, туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлар җибәрелсә, 1-2 фактик, 1-2 техник хатасы булса, 2 орфографик, 2-3 пунктуацион, 1 грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.

3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сак- ланмаса, 3 фактик, 2-3 техник хатасы булса, 3 орфографик, 4 пунктуацион, 2 грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.

4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны 4 тән артса, пунктуацион хаталарның саны 5 тән, грамматик хаталар саны 3 тән артса, «2» ле куела.

## Сочинениене бәяләү

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килүе, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге саклanса, «5» ле куела (1 орфографик яисә 2 пунктуацион хата булырга мөмкин).

2. Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлар күзәтелсә, 1-2 фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, 2 орфографик, 3 пунктуацион яисә 1-2 сөйләм ялгышы булса, «4»ле куела